РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

РЕШЕНИЕ

КАРАР

№ 27

2020 елның 23 марты

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2006 елның 13 октябрендәге 50 номерлы «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү мәсьәләсен җайга салу максатларында, Россия Федерациясе Хезмәт кодексына, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына, Түбән Кама муниципаль районы Уставына таянып, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама мунииипалҗ районы Советының 2006 елның 13 октябрендәге 50 номерлы «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «4. Конкурста катнашырга Россия Федерациясе гражданнарына (алга таба - гражданнар), шулай ук муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләренә җавап бирүче һәм әлеге Нигезләмәнең 13 пунктында каралган срокта әлеге Нигезләмәнең 9 пунктында күрсәтелгән документлар тапшырган муниципаль хезмәткәрләргә рөхсәт ителә.».

1.2. 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «5. Гражданга (муниципаль хезмәткәргә) муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләренә туры килмәүгә бәйле, шулай ук «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә конкурста катнашырга рөхсәт ителми.».

1.3. 9 пунктның 1, 4, 6 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча тутырылган һәм имзаланган анкетаны фото белән;

4) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясы);

6) конкурсны үткәрү елына кадәрге ел өчен керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат;».

1.4. 13 пунктта беренче абзацны түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга: «Документлар гражданнар тарафыннан (муниципаль хезмәткәрләр

тарафыннан) шәхсән, почта аша яисә электрон рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә күрсәтелгән мәгълүмат системасын кулланып тапшырыла.»

1.5. 21 пунктта өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми санынинан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала. Конкурс комиссиясе утырышын бары тик муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче әгъзалар катнашында гына уздыру рөхсәт ителми. Конкурс комиссиясе карарлары утырышта катнашучы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.».

1.6. 25 пунктка түбәндәге редакциядә беренче абзац өстәргә: «Кандидатлар булмаса яисә вазыйфага квалификация таләпләренә туры килә торган бер генә кандидат булса, конкурс гамәлгә ашмаган дип таныла. Бу очракта бердәнбер кандидатка, кандидатларның таләп ителә торган саны булмау сәбәпле, конкурс үткәрелмәгән дип, язмача хәбәр ителә.».

1.7. 26 пунктны түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга: «Әгәр гражданин конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырса, конкурс нәтиҗәләре аңа электрон документ рәвешендә җибәрелә.».

1.8. 27 пунктка түбәндәге редакциядә җөмлә өстәргә: «Конкурста катнашу өчен электрон рәвештә бирелгән документлар өч ел дәвамында саклана, шуннан соң юкка чыгарылырга тиеш.».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирле үзидарә, регламент һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы,
Башлык урынбасары

Э.Р.Долотказина